ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

12 июль 2024ел № 4577

Башкарма комитетның 2021 елның 31 маендагы 3670 номерлы Карары белән расланган җир эшләрен башкаруга ордер (рөхсәт) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Шәһәр Уставының 41 статьясы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2021 елның 31 маендагы 3670 номерлы Карары белән (Башкарма комитетның 2021 елның 23 ноябрендәге 7629 номерлы Карары редакциясендә) расланган җир эшләрен башкаруга ордер (рөхсәт) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) преамбулада «Башкарма комитетның 2021 елның 3 мартындагы 1441 номерлы Карары белән расланган Муниципаль һәм дәүләт хезмәтләре исемлеге» сүзләрен төшереп калдырырга;

2) 2.5.6 пунктка түбәндәге эчтәлектәге 3 пунктча өстәргә:

«3) инженерлык коммуникацияләрен эксплуатацияләү, автомобиль юлларын эксплуатацияләү өчен җавап бирә торган хезмәтләр, сак зоналарын балансta тотучылар белән, эшләр башкарылган җир участокларының хокук ияләре белән килешү (челтәр оешмалары тарафыннан башкарыла торган, энергия кабул итү җайланмаларын технологик тоташтыруны гамәлгә ашыру очракларыннан тыш)»;

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары И.С. Зуевка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов